ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында” Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына һәм “Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында” Татарстан Республикасы Законының 13 һәм $13^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 31 маенда
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында” 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясындагы 5 пунктының беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар белән бергә туры килеп, депутат вәкаләтләрен туктатуга китергән очракта, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә эшләүче депутатларга депутат вәкаләтләре туктатылган көнгә билгеләнгән вазыйфа нигезендә айлык акчалата түләүнең икеләтелгән күләмендә бер мәртәбә акчалата пособие түләнә.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында” 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7

(II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяда:

а) 1 өлештә “, гаепле гамәлләр кылуга бәйле рәвештә вәкаләтләре туктатылган очраклардан тыш, яшенә һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

“6. Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен үтәве туктатылган затка әлеге статьяда каралган өстәмә дәүләт гарантияләре аңа пенсия яшенә җиткәч яисә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда хезмәткә сәләтлелеген югалткан очракта бирелә. “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 19 статьясындагы 1 пунктының “б”, “г”, “ж”, “з”, “и” һәм “л” пунктчаларында каралган нигезләр буенча Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен үтәве туктатылган затка өстәмә дәүләт гарантияләре бирелә алмый.”;

2) $13^1$ статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

“3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры вәкаләтләрен үтәве туктатылган затка әлеге статьяда каралган өстәмә дәүләт гарантияләре аларга пенсия яшенә җиткәч яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда хезмәткә сәләтлелеген югалткан очракта бирелә. “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, кулдагы акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәүгә, бурычларны башкармауга бәйле рәвештә, йә “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 9 статьясындагы 1 пунктының “б”, “г” пунктчаларында каралган нигезләр буенча, йә “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 12 статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән чикләүләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры вәкаләтләрен үтәве туктатылган затларга өстәмә дәүләт гарантияләре бирелә алмый.”.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 10 июне
№ 41-ТРЗ